**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2018 елның 30 ноябре 16№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Яңа Үргәагар авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы нигезендә 2018 елның 19 ноябрендәге 25 номерлы «Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге гражданнарының кушымтада бирелә торган үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

ТР Әлки муниципаль районы
Яңа Үргәагар авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ә.Ә.Рәхимҗанов

Яңа Үргәагар авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 16
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү киләсе календарь елның 1 гыйнварына кадәр җирле референдумда катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Яңа Үргәагар авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 18 яшькә җитмәгәннәр, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 18 яшькә җиткән барлык гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына Иске Үргәагар авылы, Иске Үргәагар һәм Яңа Үргәагар авылы мәгълүмат стендларында һәм Әлки муниципаль районы http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтының Яңа Үргәагар авыл җирлеге битендә басылып чыгу һәм халыкка игълан итү юлы, шулай ук кәгазьдә имзалатып тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллама белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Яңа Үргәагар авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) башкаруга исәп-хисап ясау хокукына ия оешма аша яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы аша акча күчерү юлы белән башкарыла

6.Түләү фактын касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

7. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Яңа Үргәагар авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018
елның 30
ноябрендәге 16
номерлы карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ______ №
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
_____________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)

Түләүченең Ф.И.О. ____________________________________________
Адресы: ____________________________________________________
Нигездә:______________________________________________________
Сезгә бер тапкыр түләнә торган түләүне____________________ вакыты җиткәнче түләргә кирәк
________________________________________ сум күләмендә
реквизитлар :__________________________________________________
Алучының банкы БИК __________________________________
Сч. № _______________________________
Алучы Сч. № ___________________________________
ИНН ______________________________________
КПП ______________________________________
КБК _______________ ОКАТО _________________
Түләү билгеләмәсе
_______________________________________________________________
_________________________________________________________

Җитәкче ________________ _____________________
М.У. (имза) (имзаны җәелдерү)
**кисү линиясе-** - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә № ________________
Үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләүне
_____________________________________бюджетына түләү турында
(муниципаль берәмлек исеме)
суммада ________________ сум.
Түләүче Ф.И.О. __________________________________________________
Адресы: _______________________________________________
Алдым 20___ ел. "__" ________________ ____________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Киселгән өлеше хәбәрнамә тапшырылса, тутырыла һәм Яңа Үргәагар авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*